СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**01 ноябрь 2024 ел** **№ 20**

**Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Гөберчәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Гөберчәк авылында Гөберчәк авылы, М.Мәһдиев урамы, 72Б йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Гөберчәк авылында Гөберчәк авылы, М.Мәһдиев урамы, 72Б йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 15 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Г.Ахунов урамында яшәүчеләр;

2нче этап: М.Мәһдиев урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Гөберчәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган

гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру,транспорт хезмәтләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешен вак таш белән өлешчә тигезләү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(материал сатып алып китерү, буяу һәм су башнясын коймалап алу);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү; (материал сатып алып китерү, буяу һәм зират коймасын ремонтлау));

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү(материал сатып алып китерү, буяу һәм Сафый чишмәсен коймалап алу;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), табигый яисә ясалма сулык ярындагы янгын сүндерү автомобильләре өчен махсус корылмаларны төзү, ремонтлау;(материаллар сатып алу һәм янгын гидранты коесын ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторының асылмалы җиһазы чапкыч өчен пычаклар комплекты сатып алуны финанслашу) ;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Гөберчәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Гөберчәк авылы, М.Мәһдиев урамы, 72Б йорт

адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин